УДК 351.852.13

***Н.В. Герасимова***

# 1920 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАН МУЗЕЙЛАРЫ СӘНГАТИ КОЛЛЕКЦИЯЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУДА ДӘҮЛӘТ МУЗЕЙ ФОНДЫНЫҢ РОЛЕ

В статье рассматриваются процессы перераспределения художественных произведений из Государственного музейного фонда в музеи Республики Татарстан в 1920-е годы, дается анализ сложившихся в результате коллекций.

**Ключевые слова:** музей, художественные коллекции, Государственный музейный фонд, Отдел охраны памятников искусства, старины и природы НКП ТАССР.

Дәүләт музей фонды (ДМФ) 1918 елда инкыйлабка кадәрге музей коллекцияләреннән, шулай ук, национализацияләп сарай һәм алпавыт утарларыннан, аерым фатирлардан, чиркәү-монастырьлардан һәм башка учреждениеләрдән алынган берәмлекләрдән туплана башлый. Алар, саклау максаты белән, инвентаризацияләнә һәм әһәмияте буенча бүленеп, илдәге музейларга урнаштырыла. Дәүләт музей фондының нигезе сәнгати-тарихи комиссияләр, аннан соң Музей эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе һәм Мәгариф халык комиссариатының сәнгати һәм борынгы һәйкәлләрне саклау, исәптә тоту бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан салына [Путеводитель].

Музей эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе 1917 елның ноябрендә оеша. Ул музейда саклау әһәмияте булган әйберләрне национализацияләү, Мәгариф халык комиссаритының (МХК) 371 номерлы «Об объединении деятельности художественных и культурно-исторических музеев» дигән карары нигезендә МХК эшчәнлегенә ярашлы рәвештәге музейлар төзелешенең гомуми планын төзү белән шөгыльләнә; Мәскәүдәге һәм Петроградтагы мәдәни-тарихи музейлар эшчәнлеге белән идарә итә; урыннарда бу эшне губерналардагы үзләренең бүлекчәләре аша оештыра; музей эшләренең барлык мәсьәләләре буенча да карарлар кабул итә [Собрание…, 1945]. Фондның Петроград бүлекчәсендә бу эш белән В.И. Ерыкалов, Мәскәү бүлекчәсендә И.Э. Грабарь идарә итә. Җыелган сәнгать әсәрләре саклау фондларына җибәрелә: Петроградта алар Кышкы сарайга, Кронверкка, Мятлевлар һәм Бобринскийлар һ.б. йортларына, Мәскәүдә Инглиз клубы бинасына, Берг, Гершман, Зубалов хуҗалыкларына урнашкан була. Илдәге үзәк һәм җирле музейлар коллекциясе нәкъ менә шул саклау урыннарындагы әсәрләр белән тулылана да инде.

Бу процесс Казан губернасын да читләтеп узмый. 1919 елның августында Музей эшләре һәм сәнгати, борынгы истәлекләрне, табигатьне саклау бүлеге

оеша (1923 елның 1 сентябреннән ТАССР ХКС карары белән ул музей комиссиясе дип үзгәртелә). Бүлек составына профессор К.В. Харлампович, Б.Ф. Адлер, А.М. Миронов, сәнгать белгечләре В.П. Соколов, П.М. Дульский, шулай ук йөреп эшләүче интрукторлар М.И. Лопаткин, В.В. Перцов, П.А. Радимов кертелә [Протокол 25]. Казанда мондый бүлекне оештыруга РСФСР Мәгариф халык комиссариаты музей эшләре һәм сәнгати һәм борынгы һәйкәлләрне саклау бүлеге мөдире урынбасары И.Э. Грабарь (галим Казанга 1919 елның августында Казан һәм Болгарның истәлекле һәйкәлләрен өйрәнергә килә) зур роль уйный. Шул елда ук ул Казан губерна музеена (бу музей 1894 елда оеша: 1919 елда ул – Шәһәр фәнни-сәнәгый музее; 1919–1920 елларда – Казан Губерна музее; 1920–1944 елларда – ТАССР Үзәк музее; 1941–1981 елларда – ТАССР Дәүләт музее; 1981–1992 елларда ТАССР (1990 нан – ТССР) Дәүләт берләштерелгән музее; 1992–2001 елларда ТР Дәүләт берләштерелгән музее; 2001 елның мартыннан – ТР Милли музее) бүләк итеп «бер йөк картина һәм гравюралар» тапшыра. Мәсәлән: тугыз тасвир мөкатдәсен (икона) тәшкил иткән Новгород язмасы «Деисусный чин», В.К. Бялыницкий-Бирули «Март» (1914), Ф.В. Васильевның «Чебоксары» (?), С.Ю. Жуковскийның «Зимний мотив» (1901 (?)), билгесез рәссамның (П.А. Нилус булса кирәк) «Пейзаж. Этюд», П.И. Петровичевның «Пристань на Волге» (1902 (?)), И.Е. Репинның «Голова казака. Этюд» (1910), К.А. Коровинның «Розы» (1916) һәм В.Д. Фалилеевның 15 офорты. Болар музейның 25 еллыгына гаять кыйммәтле бүләк була [Дульский, 1920, с. 43]. П.М. Дульский билгеләп үткәнчә, музей тупланмасына килеп кергән бу хәзинә «Рус рәссамнары берлеге» эшчәнлеген билгеле бер дәрәҗәдә күзалларга мөмкинлек бирә [Дульский, 1920, с. 43].

Казан Губерна музеена Дәүләт музей фондының Мәскәү бүлегеннән сәнгать әсәрләре тапшыруның икенче этабы 1920 елның апрелендә уздырыла. Анда инде музей рәсем сәнгате һәм скульптура өлкәсендә барлыкка килгән яңа агымнар вәкилләре әсәрләренә байый. Мәсәлән: М.Ф. Ларионовның «Портрет», Н.С. Гончарованың «Евреи» һәм «Пейзаж», А.В. Грищенконың «Портрет», А.А. Осмеркинның «Натюрморт», О.В. Розанованың «Светопись», С.Т. Коненковның «Леда и лебедь», А.М. Гюрджанның «Леда» һ.б. [Список картин и скульптур…]. Шушы ук вакытта музей кызыклы гына тагын бер табышка ия була: ул чыгышы белән Чистай ягыннан булган Мәскәү сәүдәгәре Е.Д. Мясников тарафыннан инкыйлабка кадәр үк тупланган була. Е.Д. Мясников үз заманының сәнгать әсәрләрен туган шәһәрендә сәнгать галереясы ачу максаты белән җыя [Хроника, с. 75]. Шуңа күрә ул әсәрләр ТР Үзәк музеена гына түгел, ә Чистай шәһәрендәге Туган якны өйрәнү музеена да юллана. Бу хакта Дәүләт музей фонды сакланмасындагы әйтеп үткән сәнгать әсәрләрен музей эшләре

буенча Казан бүлекчәсе вәкиле А.Н. Тришевскийга тапшыру актында теркәлә [Акт о приеме…]. Әлеге факт Музей эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе хезмәткәрләренә карата хөрмәт уята. Алар шәхси сәнгать коллекцияләрен национализацияләү сәясәтен үткәргәндә үк, тупланмаларның язмышын хәл иткәндә аларның элекке хуҗаларының үтенечен-теләген истә тотканнар.

Казан музеена чираттагы бүләкне XX гасыр рәссамнарының С.А. Бахрушин тарафыннан тупланып, Третьяков галереясында сакланган 30 картинасы тәшкил итә. Алар арасында К.А. Коровин, А.Н. Бенуа, А.Я. Головин, Л.С. Бакст һ.б.ларның әсәрләре бар [Список картин из собрания…].

Шулай итеп, юбилей уңае белән Казан музеена Дәүләт музей фондыннан төрле тарихи дәверләрдә (борынгы чордан 1900 елларга хәтле), төрле юнәлешләрдә һәм стильләрдә (реализмнан башлап авангардчылыкка кадәр) иҗат иткән рәссамнарның 132 эше тапшырыла.

XIX гасыр чигендә һәм XX гасыр башында барлыкка килгән «Мир искусства», «Союз русских художников», «Голубая роза», «Бубновый валет» сәнгати берләшмәләре вәкилләре иҗатына аеруча зур игътибар бирелә. Казан музеен баеткан бу бүләкләрне һәм ул коллекциянең зур әһәмияткә ия өлешен сәнгать белгечләре Г.А. Могильникова [Могильникова, с. 12] белән О.Л. Улемнова югары бәяли. О.Л. Улемнова, Казан рәсем сәнгатендә авангардлык агымы көчәюгә нәкъ әнә шул хезмәтләр этәргеч бирде һәм илнең эре шәһәрләрендә, шул исәптән Казанда Сәнгати культура музее оештыру максатының ерак киләчәген дә алар билгеләделәр, ди [Улемнова, с. 12]. Җибәрелгән әсәрләрдән кызылармиячеләр һәм шәһәр эшчеләре өчен «Казанда дәүләткүләм беренче сәнгать һәм фән күргәзмәсе» оештырыла [Первая государстенная…].

1920 еллар ахырында, башкала музейларына национализацияләнгән коллекцияләр тупланып беткәч, аларның бер өлешен регион музейларына бүлеп бирү башлана. 1927 елның җәендә, мәсәлән, Казан музее элек Третьяков галереясында, Цветаева галереясында, Яңа Көнбатыш рәсем сәнгате музеенда, Строганов көллиятенең Румянцев музеенда сакланган 39 әсәргә ия була [Акт № 667]. РСФСР Мәгариф халык комиссариаты хезмәткәрләренең ел буе шушы эш өстендә нәтиҗәле хезмәт куюларын да билгеләп үтәргә кирәк. Алар музейның тулы ихтыяҗын ачыклау максаты белән, музей тупланмасының каталогын өйрәнү өчен, Махсус методологик комиссия төзиләр. Аның составына Б.П. Денике, А.М. Эфрос һ.б. керә. А.М. Эфрос 1926 елда Казанга Музейлар конференциясенә килә, шул вакытта ул музей тупланмасы белән дә таныша. Шулай ук ТР Үзәк музее сәнгать бүлегенең музей эшләре Казан бүлекчәсе хезмәткәре П.М. Дульский Мәскәүгә командировкага җибәрелә. Аның максаты Мәскәүдә җыелган материаллар белән танышу һәм картиналарның инде әзер исемлегенә кайбер

төзәтмәләр кертү була [Дульский, 1927, с. 3–4]. П.М. Дульский билгеләп үткәнчә, исемлек төзегәндә Методологик комиссия музейның Сәнгать бүлеге тупланмаларындагы җитешсезлекләрне бетерү максатын куя, чөнки Казан музеенда бу яктан сәйярлык (передвижничество) дәвере аеруча аз яктыртылган була, шуңа күрә комиссия музейга шул чор рәсем сәнгате үрнәкләрен – И.А. Айвазовский, А.П.Боголюбов, Ф.А. Васильев, В.Г. Перов, В.Д. Поленов, В.Е. Маковский хезмәтләрен мөмкин кадәр күбрәк кертергә тырыша [Дульский, 1927, с. 4]. 1920 еллар башында җанланып киткән бу эшне дәвам итеп, музейга «Мир искусства», «Союз русских художников» берләшмәләре рәссамнары М.В. Нестеров, В.А. Серов, С.Ю. Жуковский, И.И. Левитан әсәрләре дә өстәлә.

Дәүләт музей фондыннан ТР Үзәк музеена сәнгать әсәрләре соңгы тапкыр 1930 елның февралендә тапшырыла. Рус музее фондыннан 16 картинаны Казанга күчерү турындагы акт сакланган. Казанга тагын XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында иҗат иткән Н.И. Альтман, Ф.В. Боткин, И.И. Бродский, Н.П.Крылов, Н.Д. Милиоти, В.А. Серов, Н.К. Рерих һ.б. рәссамнарның әсәрләре дә тапшырыла. Әлеге чараларның оештыручысы Мәгариф халык комиссариатының музейлар эше Казан бүлекчәсе гыйльми сәркатибе һәм ТР Үзәк музееның борынгы рус сәнгате бүлеге саклаучы хезмәткәре П.Е. Корнилов була, соңыннан ул Ленинградка күчеп китә һәм Рус музеенда фәнни хезмәткәр булып эшли.

ТАССР районнарындагы музейларга килгәндә, Музей эшләре буенча Казан бүлекчәсе хезмәткәрләре тырышлыгына карамастан, аларның фонды, әйтеп үткәнчә, Чистай туган якны өйрәнү музеендагы Е.Д. Мясников коллекциясеннән, Дәүләт музей фонды әсәрләреннән кала, беркая да күчерелми. ТР Милли архивында РСФСР фән, сәнгать һәм музей учреждениеләре баш идарәсенә Казан бүлекчәсеннән 24.12.1927 датасы белән республиканың Тәтеш, Зөя, Алабуга, Чистай кантоннары (районнары) музейлары коллекциясен тулыландыруны сорап язылган документлар сакланган. Анда мондый юллар бар «желательно получить: картины русских школ, гравюры, фарфор, хрусталь и проч...» [В музейный отдел...]. Әмма, РСФСР фән, сәнгать һәм музей учреждениеләре баш идарәсенең музейлар бүлеген үзгәртеп кору белән бәйле булса кирәк, бу үтенеч җавапсыз калган.

Шулай итеп, 1919–1930 еллар аралыгында Дәүләт музей фондыннан ТАССР Милли музеена 180 берәмлек сәнгать әсәрләре килеп ирешкән һәм, әйтергә кирәк, алар музей коллекциясен сизелерлек дәрәҗәдә баеткannар да. Шәһәргә А.Ф. Лихачев (нигездә көнбатыш сәнгате) һәм О.С. Александрова-Гейнсның (XIX гасыр рус сәнгате) сәнгать галереяларын (аларда элеккеге хуҗаларының сәнгати зәвыгы чагылыш таба) тапшыру – музейның гомум коллекциясен борынгыдан башлап, XX гасырның яңа агымнарын колачлаган дәвердәге сәнгать үсешен яктыртырлык

итеп баета. Ягъни халыкларның барлык чордагы сынлы сәнгате әсәрләрен туплаган Сәнгати культура музее төзү идеясе, өлешчә, Казанда тормышка ашырыла [Искусство коммуны].

**Әдәбият**


Акт № 667. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 78, л. 43–44.

Акт НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 114, л. 162.

Акт о приеме музейных экспонатов. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 14, л. 1–2.

В музейный отдел главнауки РСФСР. НА РТ ф. 3682. оп. 1, ед. хр. 1185, л. 79.

*Дульский П.М.* Вступительная статья. // Выставка картин, выделенных государственным музейным фондом Москвы Центральному музею ТАССР. Каталог. Казань, 1927. С. 3–6.

*Дульский П.М.* Новые приобретения художественного отдела Казанского Губернского музея. // Казанский музейный вестник № 1–2. 1920, с. 35–46.

Искусство коммуны. 1918. 15 декабря.

*Могильникова Г.А.* История формирования коллекции русской живописи Государственного музея изобразительных искусств Республики Татарстан. // Русское искусство XVII – начала XX веков Живопись: каталог.

Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан. Казань: Kazan-Казань, 2005. С. 9–15.

Первая государственная выставка искусств и науки в Казани. Каталог. Казань: «Первая государственная типография», 1920.

Протокол 25 совместного заседания коллегии Казанского подотдела и Совета общества археологии. Истории и этнографии 11 августа 1920 г. НА РТ ф. 271, о. 1, е. х. 162, л. 62.

Путеводитель. // Центральный государственный архив литературы и искусства Санкт-Петербурга. 2007 [Электронный ресурс] http://guides.rasarchives.ru/browse/guidebook.html?bid=402&sid=1202105 дата обращения: 18.08.2017).

Собрание узаконений и распоряжений правительства за 1919 г. Управление делами Совнаркома СССР. М, 1943, с. 553–554.

Список картин и скульптур, отобранных из Государственного Художественного Фонда Отдела изобразительных искусств Наркомпросса для пополнения Музея в г. Казани. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 14, л. 8–9.

Список картин из собрания б. С.А. Бахрушина, переданных из помещения Государственной Третьяковской галереи, по постановлению Отдела по делам музеев и охране памятников искусства и старины Наркомпрсса, в Казанский музей. НА РТ ф. 2021. оп. 1, ед. хр. 14, л. 3–4.

*Улемнова О.Л.* АРХУМАС – мастерская художественного авангарда Казани // АРХУМАС. Казанский авангард 20-х. Каталог выставки. М.: Скорпион, 2005. С. 7–18.

Хроника // Казанский музейный вестник № 3–4. 1920 с. 75.


*Мәкалә РФФИ һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 17-14-16022 номерлы фәнни проекты кысаларында әзерләнде.*

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре*